КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 13 сентябрь г.Казань № 781

2019 елга Татарстан Республикасы карамагындагы «кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус исемле гомуми белем бирү оешмаларында балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елга түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасы карамагындагы «кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус исемле һәм интернаты булган гомуми белем бирү оешмаларында балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны;

Татарстан Республикасы карамагындагы «кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус исемле һәм интернаты булган гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми белем программаларын тормышка ашыруны һәм аларда балаларны карап тотуны финанслар белән тәэмин итү күләменә карата төзәтү коэффициентларын.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елга Татарстан Республикасы карамагындагы «кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус исемле гомуми белем бирү оешмаларында балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2017 ел, 18 сентябрь, 682 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Бу карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 13 сентябрь, 781 нче
карары белән расланды

2019 елга Татарстан Республикасы карамагындагы
«кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус исемле һәм интернаты булган
гомуми белем бирү оешмаларында
балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Гомуми белем бирү оешмасы төре | Хезмәт күрсәтүдән файдаланучылар категориясе | Урнашу территориясе | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, 1 елга сум |
|---|---|---|---|
| Интернаты булган «кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус исемле гомуми белем бирү оешмалары | интернатта яшәүче тәрбияләнүчеләр | шәһәр җирлеге | 153 320 |
| | | авыл җирлеге | 157 795 |
| | интернатта яшәми торган тәрбияләнүчеләр | шәһәр җирлеге | 68 126 |
| | | авыл җирлеге | 68 923 |

_______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 13 сентябрь, 781 нче
карары белән расланды

2019 елга Татарстан Республикасы карамагындагы
«кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус исемле һәм интернаты булган
гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми белем программаларын
тормышка ашыруны һәм аларда балаларны карап тотуны
финанслар белән тәэмин итү күләменә карата
**ТӨЗӘТҮ КОЭФФИЦИЕНТЛАРЫ**

| Т/с | Гомуми белем бирү оешмасы исеме | Төзәтү коэффициенты |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | «Советлар Союзы Герое Никита Кайманов исемендәге кадетлар мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,323638 |
| 2. | «Советлар Союзы Герое Илдар Маннанов исемендәге 82 нче кадетлар мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,317361 |
| 3. | «Советлар Союзы Герое Хәсән Заманов исемендәге Актаныш кадетлар интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,108835 |
| 4. | «Советлар Союзы Герое Газинур Гафиятуллин исемендәге Бөгелмә кадетлар интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,187811 |
| 5. | «Советлар Союзы Герое Николай Волостнов исемендәге Васильево кадетлар интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,154654 |
| 6. | «Советлар Союзы Герое Михаил Алексеевич Чириков исемендәге Кама Тамагы кадетлар интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,172967 |
| 7. | «Советлар Союзы Герое генерал-полковник Василий Николаевич Гордов исемендәге Минзәлә кадетлар интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,196306 |
| 8. | «К.С.Байкиев исемендәге Икшермә кадетлар интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учрежде-ниесе | 1,222486 |
| 9. | «Павел Алексеевич Карпов исемендәге Болгар кадетлар интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,118007 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 10. | «Генерал-майор Владимир Аверкиевич Хапаев исемендәге Тәтеш кадетлар интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,165673 |
| 11. | «Советлар Союзы Герое И.Н.Конев исемендәге Чирмешән кадетлар интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,124905 |
| 12. | «Советлар Союзы Герое Сергей Евдокимович Кузьмин исемендәге Чистай кадетлар интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,194242 |
| 13. | «Советлар Союзы Герое Б.К.Кузнецов исемендәге Казан кадетлар интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,219636 |
| 14. | «Калкан» полиция кадетлар мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,351805 |
| 15. | «Советлар Союзы Герое Гани Сафиуллин исемендәге Идел буе федераль округының Татарстан кадетлар корпусы» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,200084 |